ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БОЛЬШЕЕЛОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ОЛЫ ЕЛОВО АВЫЛ
ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** с.Большое Елово **КАРАР**

№ 10 “18” августа 2022г.

**Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Олы Елово авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы "Олы Елово авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында»2020 елның 1 апрелендәге 3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 1743 статьясы, "Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә карата гомуми таләпләр турында" 2019 елның 22 июнендәге 796 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары,"Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә карата гомуми таләпләргә үзгәрешләр кертү турында" 15.06.2002 елдагы 1081 номерлы РФ Хөкүмәте Карары, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Олы Елово авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының "Олы Елово авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең 2020 елның 1 апрелендәге 3 номерлы Олы Елово авыл җирлеге башкарма комитеты карары белән расланган салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

1.1. Тәртипнең 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарын муниципаль программаларга кертү муниципаль программалар максатларыннан һәм (яисә) муниципаль программаларга карамый торган муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый сәясәте максатларыннан чыгып гамәлгә ашырыла».

1.2. Тәртипнең 12 пунктындагы 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарының муниципаль программаларга һәм (яисә) муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый сәясәте максатларына туры килүе;».

1.3. Тәртипнең 12 пунктындагы 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

"ташламалардан файдаланган түләүчеләр саны һәм ташламаларны куллану өчен потенциаль хокукка ия түләүчеләр саны белән 5 еллык чорда күрсәтелгән ташламаларга түләүчеләрнең ихтыяҗы зур".

1.4. 12 пунктны түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

"Салым чыгымнары кураторы тарафыннан бирелгән ташламаларга түләүчеләрнең ихтыяҗын бәяләүне уздыру максатларында әлеге пунктның өченче абзацында күрсәтелгән нисбәтнең минималь әһәмияте билгеләнергә мөмкин, бу очракта ташлама кирәк дип таныла".

3. Әлеге карар рәсми басылып чыгарга тиеш.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Җитәкче А.И. Машанов